**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге Бәләкәй Пәлчекәү торак пунктында гражданнар җыены карары**

**11.11.2025** **№1**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Шепкә авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Шепкә авыл җирлегенең Бәләкәй Пәлчекәү торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Яшәү урыны буенча Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең Бәләкәй Пәлчекәү торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндез белем алучы студентлардан, I төркем инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан,Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, 2026 елда үзара салымны 600 (алты йөз) сум күләмендә кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга:
-Авыл территориясен төзекләндерү.
2.Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге Бәләкәй Пәлчекәү торак пунктының мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» кабул ителгән көннән 7 көн дәвамында урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Шепкә авыл җирлеге башлыгы Камалиева Л.М.